Н. Гасрый татар әдәбияты юллар чатында торган чакта Гаяз Исхакый иҗаты белән татар әдәбияты тарихында яңа дәвер башлануын ассызыклый. «Татар әдәбияты билгесез юллар чатында торган вакытта 1897 елда әдәби аренага Гаяз Исхакый чыга. Ул күренү белән, татар әдәбияты үсешендә яңа дәвер, татар матур әдәбиятының үсеше, реализм юлында кискен борылыш еллары башлана» [Неджиб, 1911, с. 173] Тәнкыйтьче, әдәбият проблемаларыннан тыш игътибарын татар теле мәсьәләләренә дә юнәлтеп, Гаяз Исхакыйны татар әдәбиятына нигез салучы, ә “татар әдәби теленең атасы” дип билгели. Беренче рус инкыйлабы белән ташкын булып поэзиягә килеп кергән шагыйрьләр арасыннан ике шагыйрьне – Габдулла Тукай һәм Сәгыйт Рәмиевне аерып ала. 1905-1910 еллар шигъриятендә, халык теләк-омтылышлары, моң-зарлары белән сугарылып, татар тормышын тулы сурәтләргә омтылган халыкчан реалистик поэзияне һәм, мул поэтик бизәкләргә төреп, лирик-шәхси кичерешләрне калкытып куйган романтик поэзия юнәлешләрен билгели.

1910 елларда, милли рамкаларда гына калмыйча, Ауропа киңлекләренә омтылган сүз сәнгатен бәяләү һәм аның үсеш юлларын билгеләү бурычы йөкләнгән татар әдәби тәнкыйтен камилләштерү, аның дәрәҗәсен күтәрү мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Бу уңайдан аның “Әдәбиятымыз мөнәкъкыйдкә мохтаҗ” (1913) мәкаләсе язылa. Н. Гасрый дөнья һәм төрки-татар әдәбиятында шартлы-романтик кулланылышның гаять бай, үзенчәлекле традицияләре булган *бакча, су, яктылык* символларына мөрәҗәгать итеп, әдәби тәнкыйтьнең матур әдәбият үсешендә тоткан роле, тәнкыйтьченең абруе турында үз бәя-хөкемнәре белән уртаклаша [Гасрый, Әдәбиятымыз..., 1913]. Автор тәнкыйтьне “әдәбиятның тәрәккыйсендә иң әһәмиятле бер гамәл” буларак карый, “матур әдәбият

әсәрләрен бәяләүдә әдәби тәнкыйтьтә объективлык принцибын тәкъдим итә" [Мухамадиев, с. 16].

Н. Гасрыйның татар әдәбиятының яңарышында хәлиткеч роль уйнаган язучыларның күренекле әсәрләрен яисә аларның тулаем иҗатын бәяләгән мәкаләләре дә басыла. Аның иҗат портреты жанрындагы "Шимали төрек әдипләреннән Гаяз Исхакый" язмасы дөнья күрә. Тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашлары, әдәбият-сәнгатькә мөнәсәбәте мәсләктәше Г. Исхакый тәэсирендә формалаша. Ул культура-тарих мәктәбенең төп кагыйдәсенә нигезләнеп, сүз сәнгатенең вазифасын милләткә хезмәт итүдә, аның үсешенә файда итүдә билгели: "... мөхәррирнең әсәр язудан максаты "сәнгать күрсәтү" түгел, ә мәгънәдер" [Исхакый, 2001, 8 т., 164].

Н. Гасрый язучы иҗатының идея-эстетик үзенчәлекләрен, жанр таләбенчә, аның тормыш баскычларындагы мөһим вакыйгалар белән синтезлап алып бара. Мәкалә авторы Исхакыйның әлеге вакытка кадәрге әдәби эшчәнлеген ике чорга бүлә: беренчесе – "милләтпәрвәрлек", икенчесе – "гавампәрвәрлек". Һәр чорның иҗат җимешләрен атый һәм аерым берләренә җентекле анализ ясый. "Ике йөз елдан соң инкыйраз" повестен беренче иҗат чорының иң күренекле әсәре дип саный. Г. Исхакыйның милли сүз сәнгате тарихындагы ролен "яшь татар әдәбиятына ныклы нигез коручы һәм ул әдәбиятның иң зур вәкиле" төсендә югары бәяли, иҗатының реалистик стилен һәм халыкчан рухын, гәүдәләнгән темаларның иҗтимагый-милли характерын аерып куя.

Г. Ибраһимовның сәнгатьчә эшләнеше югары булмаган "Яшьләр хәятеннән бер ләүхә" хикәясе басылып чыгып, 5-6 ел узганнан соң, тәнкыйди һәм иҗтимагый фикернең игътибарын үзенә тарта һәм вакытлы матбугатта С. Рәмиев, Җ. Вәлиди язмалары дөнья күрә. Н. Гасрый "Ил" газетасында Г. Ибраһимов хикәясенә язылган "Яшьләр хәятеннән бер ләүхә" рецензиясен бастыра [Гасрый, 1914, Яшьләр хәятыннан...]. Автор әсәрнең проблематикасы уңаеннан XIX – XX гасыр чикләрендә татар яшьләре, алардагы фикер хәрәкәтенә кыскача күзәтү ясап, "фәлсәфә", "милләтчелек", "инсаниятчелек" үсеш-үзгәреш баскычларын аерып чыгара.

Ике гасыр чигендәге татар яшьләре хәрәкәте тарихына характеристика биргәннән соң, автор, бу хәрәкәтнең гәүдәләнеше булган Сәлимнең образ буларак бирелешен бәяли. Хикәядә сурәтләнгән вакыйгаларның герой рухында һәм мәсләкләрендәге үзгәрешләрне ачмавын, фикри көчешләрнең Сәлим эшчәнлеге аша исбатланмавын ассызыклый. Язучы "гали рухлы" дип тәкъдим иткән Сәлимнең өч-дүрт ел эчендә туктаусыз мәсләк алмаштыруы аның характер сыйфатына туры килмәвен күрсәтә [Гасрый, 1914, Яшьләр хәятыннан...].

Н. Гасрыйның рухи мирасында милли шигърият, аның асылы, гомуми торышы һәм үсеш тенденцияләре, татар поэзиясенең аерым вәкилләре иҗаты хакында язмалар да бар. Шундыйларның берсе З. Бурнашеваның дөнья күргән шигырьләре китабына рецензия-мәкалә жанрында язылып, "Ил" газетасының 1915 елгы 4, 11 март саннарында басылган "Гыйффәт туташ шигырьләре" дип атала. Ул татар матбугатында хатын-кыз шагыйрә иҗатына багышланган тәүге күләмле язма булуы, татар дөньясында Н. Гасрыйның З. Бурнашева хакында беренче сүзне әйтүе ягыннан да игътибарга лаек.

Мәкаләнең башлам өлешендә Н. Гасрый поэзия, аның асылы, сәнгатьнең башка төрләреннән, әйтик музыка, рәсем, скульптурадан аерымлыклары, милли шигъриятнең үсеш тенденцияләре турында үз карашлары белән уртаклаша. Тәнкыйтьче язучылык һөнәре, шагыйрьлек сәләте, талант турында уйланганда, Г. Ибраһимов нигез салган "рухиятчеләр" мәктәбе сызыгына төшеп, аның табигать тарафыннан бирелүен, илаһи көч булуын ассызыклый һәм шул ук вакытта талантның тәрбия ителүен, гыйльми-нәзари мәгълүмат белән ныгытылуын да зарури шарт буларак карый [Гасрый, 1915, Гыйффәт туташ...].

Язма авторы шушы гыйльми күзаллаулары яссылыгында Гыйффәт туташның әсәрләрен анализлауга күчә. Н. Гасрый З. Бурнашеваның шигырь җыентыкларын 1914 елның шигърият күгендә "моңлы, кадерле йолдызлар" рәвешендә бәяли һәм аны татар поэзиясендә хис-калеб шагыйрәсе, "тойгылар шагыйрәсе" буларак карый. Шагыйрәнең шәхси, индивидуаль күңел кичерешләрен җырлавына басым ясала. Шул рәвешле Гыйффәт туташның шигърияткә килү, әсәрләренең идея-эчтәлеген билгеләгән кичерешләрнең сәбәпләре күрсәтелә.

Н. Гасрый рецензия-мәкаләсендә әдәби йогынты, әдәби тәэсир, әдәбиятара бәйләнешләр, XX гасырның урталарында

фәнни әйләнешкә кергән интертекстуальлек мәсьәләсен күтәрә һәм ул бу фәнни проблеманы Гыйффәт туташ һәм күренекле татар әдәбияты классигы, шагыйрь Г. Тукай шигъриятләре мисалында карый. Тәнкыйтьче Гыйффәт туташ лирикасына шагыйрь иҗатының йогынтысы аз булуын искәртә. Тукай иҗатының замандашлары поэзиясенең идея-эстетик үзенчәлекләренә һәм тел-өслүбенә йогынтысын тикшергән Г. Сәгъди, киресенчә, З. Бурнашеваның Тукайның шәкерте булуын раслый [Сәгъди, 1923, б. 6]. З. Бурнашева – Тукай шигъри бишегендә тәрбияләнгән, "Тукай поэтик мәктәбе" шагыйрәсе. Гыйффәт туташ лирикасы белән Г. Тукай иҗаты арасында эчке-мәгънәви һәм тышкы бәйләнеш бик тә көчле. Шагыйрә үз поэзиясен, иҗат тәҗрибәсен бөек Тукайдан һич тә аермый; киресенчә, шагыйрьнең үзенә ясаган бәрәкәтле тәэсире турында горурланып яза һәм үзен Тукай традицияләре дәвамчысы дип саный.

Язманың соңгы өлешендә Н. Гасрый шагыйрә әсәрләренең эстетик табигатен тикшереп, идея-эстетик хосусиятләрен барлый. Шигырьләрендә шагыйрә-авторның җаны, рухы, калбе кичерешләре чагылу, образлылык, сурәтлелектән тыш тел-өслүб матурлыгы, сөйләм җиңеллеге, нәфислеге бизмәннәренә таянып, Гыйффәт туташның романтик поэзия вәкиле булуы хакында төп гомумиләштерүләрнең берсен ясый. Татар әдәбиятында яңа тип романтизмны биек үрләргә меңгерәчәк күңелнең хатын-кыз күңеле булуына чын күңелдән сөенә.

Н. Гасрыйның тәнкыйди мирасында элгәрге чор әдәби әсәрләрен бәяләгән язмалар да бар. Аның мәгърифәтче язучы М. Акъегетнең күренекле романына багышланган күләмле "Хисаметдин менла (Акъегетзадә Муса әсәре). Бер тәхлил әдәби" исемле рецензиясе "Аң" журналының 1915 елның ике санны берләштергән 9-10, 23-24 саннарында дөнья күрә. Тәнкыйтьче М. Акъегетнең романын әдәби барыш, аның үсеш закончалыклары хакындагы гыйльми күзаллаулары нигезендә яңа заман сүз сәнгатенең башлангычы, беренче "бисмилласы" дип бәяли. Аның бу карашы меңъелдан артык тарихы булган татар әдәбиятының дәверләрен аерып чыгарган күренекле әдәбият галиме Г. Ибраһимов тарафыннан яклана. Галим борынгы кадим дәвердән соң килгән җәдит дәверенең М. Акъегетнең "Хисаметдин менла" романы белән башлануын ассызыклый: "Икенче – җәдит әдәбият: бу дәвер моннан 30 ел элек чыккан Муса Акъегетзадә әфәнденең "Хисаметдин менла"сы белән башлана" [Ибраһимов, 1978, б. 290].

Н. Гасрый культура-тарих мәктәбенең кагыйдәсе буенча татар әдәбиятының вазифасын милләткә хезмәт итүдә, аның мәдәни үсешенә файдалы булуда билгели: "Без шигырь вә әдәбиятка сәнгать күзе белән карый алмыйбыз; без әдәбиятны эшләтергә, аннан файдаланырга, аннан матди файда күрергә тотынабыз. Яңа әдәбиятымызның беренче сәхифәсен тәшкил иткән "Хисаметдин менла" моңарга кисеп куйган үрнәк" [Гасрый, 1915, Хисаметдин менла, б. 192].

Н. Гасрый яңа әдәбиятның үрнәге булган бу әсәргә "иске әдәбият"ның фикри-мәгънәви һәм форма ягыннан йогынты ясавын билгели. Автор карашынча, урта гасырлар әдәбияты чыгтай әдәбияты һәм "җәнүби – госманлы әдәбият"лары белән тыгыз бәйләнештә яши. Ул шушы мөнәсәбәт илә ике әдәбиятның да тарихына кыскача күзәтү ясый. Ике әдәбиятның үсеш баскычлары, үзгәреш тенденцияләре, күренекле язучылары, аларның иҗатында гәүдәләнгән тема-мотивлар, тел-өслүб үзенчәлекләре, образ-тасвирлар аерып чыгарыла.

Тарихи экскурстан соң Н. Гасрый "Хисаметдин менла"ны бәяләүгә күчеп, анда шул чорның актуаль иҗтимагый һәм милли проблемалары күтәрелүен яза. Язучыда милли тойгының З. Бигиевкә, Р. Фәхретдиновка караганда көчле булуын биографик метод принципларына нигезләнеп аңлата, тормышындагы аерым фактлар белән бәйли: "Анда милли хиснең иртә яфрак яруына, бер яктан, "Тәрҗеман" сәбәп булган булса, икенче яктан, рус мәктәбендәге тәрбиянең гакес (кире. – *Т.Г.*) тәэсире, яки аның Акъегет укыган вакыттагы тәэсирсезлеге" [Гасрый, 1915, Хисаметдин менла, б. 193]. Әдәби әсәрдә үзәккә шәхес ирege, шәхес азатлыгы проблемасының куелуын күрсәтә [Татар әдәбияты, 1985, б. 293]. Ул романның төп каһарманнары Хәнифә һәм Хисаметдин менлаларның дөньяга карашлары һәм гамәлләре аша күрсәтелә. Рецензент карашынча, шәхес ирege кеше тормышындагы иң кыйммәтле сыйфат: "Инсан мәгыйшәтендә бер бәһалы вә яхшы шәй – хөррияттер: без үз хөрриятемезне саклый белермез" [Гасрый, 1915, Хисаметдин менла, б. 419 ]. Шәхес ирege мәсьәләсе милли чынбарлыкта хатын-кыз

урыны, никах иреге, хатын-кызларга белем бирү проблемалары белән үрелеп китә. Мәкалә авторы Хәнифәнең, Р. Фәхретдиновның “Сәлимә яки гыйффәт” әсәрендәге идеаллаштырылган Сәлимәдән аермалы буларак, үз бәхете өчен көрәшүен ассызыклый һәм аны Г. Исхакыйның “Алдым-бирдем” (1907) драмасының үзәк каһарманы Галия белән янәшә куя.

Алга таба мәкалә авторы Хисаметдин менлага характеристика бирә. Ул Төркиядә укып кайтып, үз өендә яңа ысул белән балалар укыта һәм тиз арада укырга, язарга өйрәнгән балаларның аталарында яклау таба. Аның өстенә ул булдыклы һәм һөнәрле егет, игенчелек белән шөгыльләнә [Гасрый, 1915, Хисаметдин менла, б. 193]. Тәнкыйтьче М. Акъегетзадәнең мәгърифәтчелек реализмы агымы принципларыннан чыгып үз геройларын мәгълүм бер идеал яктылыгында сурәтләвен ассызыклый. Язучы геройларның югары әхлаклылыгын иң мөһим сыйфат дип саный.

Н. Гасрый романда вакыйгалар үстерелешен тәэмин иткән тискәре геройлар Бикбулат мулла, авылның иң зур бае Гали бәк Җаватов белән таныштыра. Тәнкыйтьче Бикбулат мулланы анализлаганда, “тип” терминына мөрәҗәгать итә, ягъни ул шул чорның иске карашлы, кадим, әхлаксыз руханиларның гомумиләштерелгән тибы [Гасрый, 1915, Хисаметдин менла, б. 416]. Укуукыту ысулы, белем бирүнең нәтиҗәлелеге мәсьәләсенә нисбәтле Бикбулат менла белән Хисаметдин менла арасында туган төп конфликт күрсәтелә. Үзәк конфликтның ярдәмче каршылыклар белән һәрдаим тирәнәйтелеп баруына басым ясала.

Н. Гасрый “Хисаметдин менла” романындагы Әбүзәр бәкне, Хисаметдин менланы, Хәнифә туташны хәзерге вакытта татар зыялылары төркемендә барлыкка килгән милләтпәрвәрләрнең, милләт хадимнәренең прототиплары, образлары дип карый. Ф. Әмирханның “Тигезсезләр” (1914) драмасы дөнья күргәч, татар чынбарлыгында Рөкыяләр җитешүен инкарь итеп, Ф. Сәйфи-Казанлының “Ялтыравыклы ялган” (1916) бәхәсле мәкаләсе басыла. Аңа җавап төсендә Х. Искәндәровның Тигезсезләр”дә Рөкыя” (1916) язмасы нәшер ителә. Ул анда, Н. Гасрый фикерләренә аваздаш карашлар үткәреп, рухи яңарыш юлындагы татар тормышында Рөкыя, Камилә, Фатыймаларның тәрбияләнә алуын, хәтта аларның инде татар галәмендә барлыгын раслый (Кара: [Гыйлаҗев, 2008, б. 92-93]).

Н. Гасрый М. Акъегетзадә әсәренең сәнгати үзенчәлекләренә дә бәя бирә. Ул язучының хат алымына максатчан мөрәҗәгать итүен уңай бәяли. Хат алышуның төп каһарманнарның күңел кичерешләрен, характерларын, карашларын, үзара мөнәсәбәтләрен тулырак ачу вазифасын билгели. Шулай ук хатлар саф, илаһи мәхәббәтне, сөю-сөелү хисләрен зурлауга да хезмәт итә. Романда авыл халкы тормышының реаль детальләрдә гәүдәләнеше, аның яшәү рәвеше, этнографик үзенчәлекләре, туй йолалары, милли гореф-гадәтләре сурәтләнеше билгеләнә. Күңел монологларының төп каһарман Хәнифәнең эчке дөньясын, психологик кичерешләрен ачудагы роле әйтелә. Үз теләгеннән башка яратмаган кешегә бирелгән Хәнифәнең туй көннәре алдыннан булган борчылулы күңел халәте монолог ярдәмендә гәүдәләнә. Табигать тасвирларының, пейзаж алымының вакыйгалар вакытын һәм урынын конкретлаштырудан тыш, геройларның психологиясен ачу идея-эстетик вазифасын билгели.

Н. Гасрый 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң төзелә башлаган социалистик җәмгыятьтә үз урынын табарга омтыла. Яңа социаль һәм мәдәни шатларда әдәбиятка һәм сәнгатькә куелган яңа таләпләр ноктасыннан әдәби әсәрләргә һәм фәнни хезмәтләргә бәя бирә. Аның “Эшче” газетасының 1926 ел 20 гыйнвар санында Г. Нигъмәтинең “Әдәбият мәйданында” (1925) дигән монографиясенә рецензиясе басылып чыга. Тәнкыйтьче китапның кыйммәтен 1880 еллардан алып хәзерге көннәргә кадәр Гареб мәдәнияте йогынтысында үскән татар әдәбияты ирешкән казанышларны гомумиләштерүдә, аларны билгеле бер системага салуда бәяли. Ул галимнең, чит ил һәм рус галимнәре хезмәтләренә таянып, реализм, романтизм, символизм, имажинизм, футуризм методларының типологик характеристикасын бирүен һәм шуның нигезендә татар классик һәм яшь язучыларның иҗатларын анализлавын билгели. Рецензент Г. Нигъмәтинең әдәби хәрәкәтне, әдәби әсәрне тикшерү методикасының аерым сыйфатларын барлый, ягъни аның әдәби күренешкә комплекслы һәм системалы якын килүен күрсәтә.

Тәнкыйтьче карашынча, Г. Нигъмәти матур әдәбиятны башка сәнгать төрләре, сынлы сәнгать, җыр һәм музыка белән бәйләнештә

шәрехли. Э. Нигъмәтуллин Н. Гасрыйның фәнни иҗатны бәяләү методикасының үзенчәлеген нәкъ шушы ноктадан бәяли: “Әдәбиятчы Нәҗип Гасрый китапның гомумиләштерү, нәзари сыйфатын һәм авторның әдәби иҗатны эстетика һәм башка сәнгать төрләре, мәсәлән, музыка, сынлы сәнгать белән бәйләп тикшерү омтылышын ассызыклап, аны соклану хисе белән кабул итә” (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Т.Г.*) [Галимджан Нигмати…, с. 222], дип яза Э. Нигъмәтуллин. Мәкалә авторы үз күзәтүләре нигезендә татар нәфис әдәбияты гына түгел, ә музыка, рәсем сәнгатьләре дә “Гареб сәнаигы нәфисә сараенда” үзенә лаек урын алачак дигән нәтиҗәгә килә.

Тормыш-чынбарлыкны һәм иҗатчының рухын, хис-хыялын сурәтләгән реализм һәм романтизм юнәлешләрен үзләштергән татар әдәбияты дөньяны танып-белү, яшәешнең асылына төшенүнең яңа юлларын эзли башлый. Иҗат әһелләре фәлсәфи тәгълиматларны, гыйльми концепцияләрне, әдәби-эстетик системаларны өйрәнәләр. Яңа мәгънәви эчтәлекне гәүдәләндерү, сүз сәнгатен нәфисрәк һәм тәэсирлерәк итү максатыннан, Аурупа һәм Рус мәдәниятләрендә калыплашкан модернистик алымнарга һәм сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәләр. Татар әдәбиятындагы яңа дулкынга Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Ш. Камаллар белән бергә, әдәби иҗатка дөньяви уку йортларында белем алган Г. Рәхим. Г. Гобәйдуллин, М. Кайбышев һәм башкалар кушылып китә. Алар арасында Н. Гасрый да бар.

Н. Гасрыйның “Гыйшкым хәрабәләре” (1916) исемле әсәре Шәрык һәм Гареб сүз сәнгатьләре эстетик казанышлары һәм традицияләре синтезында язылган. Сабый вакыттан ук яраткан Искәндәрнең Ләйләгә гашыйк булуы Гөлнар ханымны авыр кичерешләргә, ялгызлыкка дучар итә. Аның сызланулы күңел халәте көзге табигать, агачлардан өзелеп төшкән сары яфраклар фонында тасвирлана. Көз, яз, кыш фасыллары, *бакча, яфрак* образлары татар әдәбиятында бик актив кулланылып, фәлсәфи мәгънә белдерүгә хезмәт итәләр, “.. көзге бакча үлем, өметләр өзелү, мәхәббәт һәм бәхеткә булган ышанычның юкка чыгуын искәртә” [Заһидуллина, 2007, б. 11]. Көчле позициягә ия булып, әсәрнең исеменә чыгарылган *хәрабә* символы кире кагылган мәхәббәткә, яшәү гаме һәм тормыш яме югалуга ишарә ясый. Әсәрдә җан яраткан бер була, чын сөю, ярату хыянәтне кичерә алмый дигән фәлсәфи фикер үткәрелә. Хикәядә мәхәббәт темасы һәм мәгъшукаләр матурлыгы илаһилаштырылып, Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре синтезында күрсәтелә.

Чор сүз сәнгате эзләнүләренә, бу юлда ясалган тәҗрибәләргә кушылып, Н. Гасрый яшәешнең акыл белән аңлап бетерү мөмкин булмаган яшәү һәм үлем, фанилык һәм мәңгелек проблемаларын яктырткан “Мәзарстанда” (1916) әсәрен яза. Көзге матур көннәрнең берсендә хикәяләүче үлеменең сәбәбе ачыкланмаган сөйгән кызы Ләмиганның каберен зыярәт кылырга дип өеннән чыга. Ул зираттагы серле тынлыкны бозган бер кыз баланың Коръән укыган кебек ишетелгән тавыш астында юлын дәвам итә. Герой - күптән вафат булган карт, алкоголик ире суеп үтергән хатын, ике егеткә гашыйк булып үзенең үлеменә сәбәпче булган кыз, үз-үзенә кул салган егет каберләре аркылы уза. Ниһаять, Ләмиган кабере янына барып җитеп, үткән бәхетле көннәрне күзаллап, күз яшьләре түгә. Егетнең күңел монологында сөю хисләренә, яшьлек мәхәббәте Ләмиган матурлыгына мәдхия укыла. Алга таба автор тарафыннан аң белән кабул итеп бетерү мөмкин булмаган дини-мистик күренешләр аша мәгъшука образы илаһилаштырыла: кызның кабер сакчысы итеп утыртылган “яшь, матур, чинар агачының яфраклары тәсбих әйтә” башлыйлар, кыз кабере өстеннән “нурани ак бер шәүлә күтәрелеп”, егетне билгесез матурлыгы белән сарып ала. Күпмедер вакыт серле халәттәге хикәяләүче үз хәленә килә һәм, тынычланып, кайтырга дип юлга чыга.

Озак вакытлар үтүдән ташлары мүкләнеп беткән кабер янында таш астыннан карт укыган аять ишетелә, дөнья кинәт үзгәреп, зиратта кыямәт башлана. Үлекләр кубарылып җир өстенә чыга”; “зур, ак сакаллы, ак кашлары күзләрен каплап тора торган бер карт” таш өстенә утырган да, сүрә укый; “мәгъшука кайгысыннан үзен үзе чалган яшь егет кәфенен сөйрәп” кабер ташының өстенә чыгып, башын кулларына куеп утырган һ.б.лар. Төрле тарафтан, аһ-зарлар, төрле тавышлар ишетелгәндәй була.

Г. Сәгъди бу әсәрне, Мәскәүдә нәшер ителеп, бүген дә фәнни кыймммәтен югалтмаган “Символизм турында” (1931) монографиясендә чәчмәдә “урыс әдәбияты тәэсирендәге” символизм үрнәге буларак бәяли. “Нәҗип

Гасрыйның “Мәзарстанда” (“Аң”, №5, 1916) дигән һәм бик көчле каләм белән язылган лирик хикәясе шуның ачык мисалы. Ул бу юлда иң характерлы бер хикәя” [Сәгъди, 1931, б. 113-114]. Галим язучының мондый эчтәлектәге хикәяләренең француз декадент әдәбияты тәэсире астындагы госманлы сүз сәнгатенең күренекле язучысы Халит Зыяның “Кабердән тавышлар” әсәре йогынтысында иҗат ителүен күрсәтә.

Символизм агымында язылган хикәянең яшерен эчтәлеге символик образлар, сурәтләр ярдәмендә белдерелә. Әсәр “Аһ сихерле, серле хәят! Син яшим! – дип, комга басасың; ул синең аяк астыннан тая, кача бара!” дигән хисси-эмоциональ яңгырашлы, шартлы сурәтләргә бай җөмлә белән каймаланып алынган. Ул яшәү, кеше тормышы, аның теләк-омтылышлары ялган, иллюзия генә дигән экзистенциаль фикерне белдерүгә хезмәт итә. “Кыямәт көне” каберләреннән кубарылып чыккан үлекләр арасында кеше гомерен өзгән, дин-шәригать кануннарына, дини өйрәтүләргә буйсынмыйча, үз-үзләренә кул салганнар бар. Н. Гасрый Аллаһы Тәгалә каршында олы гөнаһлар кылган кешеләргә теге дөньяда җиңел түгел, алар анда тынычлыкка ирешә алмыйлар дигән дини күзаллауны да раслый. Әсәрдәге образ-сүзләрнең символик табигатенә, әсәрнең фәлсәфи-экзистенциаль эчтәлегенә әдәбият галиме Ф. Бәширов та игътибар итә [Бәширов, б. 248].

Н. Гасрыйның, милли тарихка мөрәҗәгать итеп, иҗтимагый-фәлсәфи фикерләрен сәнгатьчә гәүдәләндергән “Соңгыр хан түбәсендә” дигән хикәясе “Аң” журналында 1916 елның 2 санында басыла. Кечкенәдән әбисеннән Соңгыр хан турында әкиятләр тыңлап үскән малай, зур шәкерт булгач, ханның образын хыялында тудыра. Мөселманнар ханы булган Соңгыр хан, атланып йөри торган аргамагы картайгач, чикләвек агачыннан көмеш белән каплатылган ишекле абзар салдыра. Рәхимле һәм шәфкатьле хан үз сараенда фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне җыеп кунак итә, ә фәкыйрь-фокара ашап-эчеп туйганнан соң, аларга берәр аяк-касә кымыз бирелә, соңыннан хан заманында сугылган акчалар өләшенә. Халык ханга рәхмәт йөзеннән аның сәламәтлегенә кычкырып дога кыла. Хан үз сараенда шул заманның галимнәрен, мөнәҗәтчеләрен, Гали хәзрәтне, Сәид Баттал Газине, думрада көйләп җыр әйтүчеләрне, сарай шагыйрьләрен тоткан. Хан картаеп үлгәч, аның табутын ука белән урап, шәһәрдән зыярәткә хәтле көмеш акчалар чәчеп алып килеп, кызыл түбәгә җирлиләр.

Хикәядәге *Соңгыр хан* төрле мәгънәви яссылыкта укылу мөмкинлегенә ия символ булып тора. Д. Заһидуллина аны “милләтне яшәткән, дәүләтчелекне саклаган, бүген дә авторлар шушы идеалга милләтне уяту, терелтү миссиясен йөкләгән” “нәби” төшенчәсе белән бәйләп карый [Заһидуллина, 2003, б. 59]. Аның мәгънәсен Урта гасырлар татар әдәбиятында гәүдәләнгән гадел хөкемдар идеясе, “камил инсан” өйрәтүе, мөселман мәдәниятендә пәйгамбәрләрне һәм галимнәрне белдергән “көтүчеләр” мәгънәсендә дә шәрехләргә мөмкин. Әсәр ахырында шәкерт күзалдында “агарган кашлары күзләренә төшкән” Соңгыр хан рәсеме җанландырыла һәм аның күңелен милли хис били, тарихи хәтер уяна: “Мине әллә нинди мөбһәм (билгесез. – *асс. Т.Г.*) бер тарихи, милли тәэсир чорнап алып кувәи хыялиямне татар тарихының киңлекләренә, парлаклыкларына (шанлылыкларына. – *асс. Т.Г.*) таба суза: Ханнар, Хан заманнары...” [Гасрый, 1916, Соңгыр түбәсендә, б. 33]. Менә бу алым символның иҗтимагый-милли мәгънәсен көчәйтә. Н. Гасрый бу хикәясендә дә татар милләтен инкыйраздан саклап калуга, мәдәниләштерүгә хезмәт итүче “рухи юлбашчылар”, голәмалар, шәхесләр һәм үзе дә шуның бер өлеше булган язучылар җитештерү мәсьәләсен сәнгати формада гәүдәләндерә.

XX гасыр башында - Исхакыйлар - Тукайлар чорында - мөстәкыйль үсеш сукмагына чыккан татар публицистикасын үстерүгә Н. Гасрый да үз өлешен кертә. Публицист замандашларыннан аермалы буларак, марксизм тәгълиматының иҗтимагый үсеш сыйнфый көрәш белән тәэмин ителә дигән постулатына каршы килеп, тарихи барышта аерым шәхесләрнең роле турында уйлана. Шуңа күрә аның бер шәлкем публицистик язмалары татар халкының кискен тарихи һәм иҗтимагый үзгәрешләр чорында, “тарихка булышучы, тарихның акрын гына, форсат белән генә эшләячәк эшен ашыктыручы куәтләр”гә [Вәлиди, б. 119] багышланган. Бу типтагы мәкаләләр шәлкемен, татар әдәбиятына сыйфат үзгәрешләре алып килеп, аны дөнья аренасына чыгарган халык шагыйре Г. Тукайның вакытсыз үлеме мөнәсәбәте белән “Идел” газетасының 1913 ел 5 апрелендә басылган “Тукаев вафат” тәгъзиясе башлап җибәрә. Ул, мәрсия жанрына хас булганча,

купшы, бизәкле тел белән язылып, Тукайны зурлый. Әмма язма, бөек шагыйрьне югалту белән бәйле юксыну, сыктау хисләре белән сугарылу сәбәпле, некролог-сыктау жанрына якын тора [Гыйлаҗев, 2008, б. 175].

Н. Гасрыйның Г. Тукайга ихтирами мөнәсәбәте аның рухи юлбашчысы татар реалистик әдәбиятына нигез салучы Г. Исхакый йогынтысында формалаша. Бу язма авторының фикер агышында күзәтелә. Ул некролог-сыктауда шагыйрьнең үлемен тар татар мохите, шыксыз милли чынбарлыкның аңа тискәре тәэсире, татар милләтенең бөек шагыйрьгә битарафлыгы, илтифатсызлыгының нәтиҗәсе итеп карый.

Татар зыялысы, мәгърифәтче, төрки халыкларның мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүгә һәм яңартуга зур көч куйган Исмәгыйль бәк Гаспралы вафат булгач, вакытлы матбугат битләрендә Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Баттал, М. Бигиев, Г. Буби, Һ. Максуди, С. Максуди һәм башкалар чыгыш ясый. Н. Гасрыйның да Исмәгыйль Гаспралының вафатына нисбәтле язылган "Алтын төрек егылды" дигән некролог-сыктавы 1914 елның 25 сентябрендә "Ил" газетасында басыла. Язма сыктау, кайгы хисе белән сугарылган. Мәкалә авторы милли мәгарифне яңартуга, һәр төрек-татар күңелендә милли үзаң уятуга, татар вакытлы матбугатын, матбагачылыкны үстерүгә, "фикердә, сүздә һәм эштә берлек" идеясен яклап, барлык көчен Россиядәге төрки халыкларның мәдәни үсешенә багышлаган Исмәгыйль Гаспралыны "*алтын төрек*" дип атый.

Н. Гасрыйның "Шиһаб хәзрәт" мәкаләсе, Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 100 ел, вафатына 25 ел тулу уңаеннан язылып, "Ил" газетасының 1915 елның 2 гыйнвар санында дөнья күрә. Юбилей мәкаләсе жанрындагы язмада публицист Ш. Мәрҗанинең татар халкы мәдәнияте тарихында тоткан урынын һәм гыйльми эшчәнлегенең кыйммәтен билгеләргә омтыла. Н. Гасрый Ш. Мәрҗани кебек олуг затның көрәш мәйданына чыгуын заман, мохит белән сәбәпле бәйләнештә аңлата [Гасрый, 1915, Шиһаб хәзрәт]. Мондый олуг затларның саны бармак белән генә санарлык булса да, татар милләтенең аларны тиешле югарылыкта зурлый, кадерли алмавына үкенү хисен белдерә.

Н. Гасрый Ш. Мәрҗани киңкырлы эшчәнлегенең төп тармакларын аерып чыгара. Мәкалә авторы аны, иң беренче нәүбәттә, үз чорының зур илаһият галиме, дини реформатор буларак бәяли һәм, икенчедән, галимнең милли тарихны барлау һәм язу юнәлешендәге эшчәнлеген аерып күрсәтә һәм аны "милли тарихчы" дип атый. Мәкалә авторының Ш. Мәрҗани турындагы фикерләре Җ. Вәлиди, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Тукай һәм башкаларның бәя-хөкемнәре белән аваздаш.

Н. Гасрыйның "Мәдрәсә мәсьәләсе" (1914) мәкаләсе эчтәлеге белән, бер яктан, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камаллар публицистикасындагы проблематикага, икенче яктан, үзенең алда шәрехләнгән язмаларындагы тарихи барышта, милләт тормышында шәхесләр, юлбашчылар роле мәсьәләсенә барып тоташа. Мәкаләдә мәдрәсәләрдә муллалар, татарларда университетлар булмау сәбәпле, мөгаллимнәр, милләт хадимнәре җитештерү проблемасы үзәккә куела. Публицист карашынча, заманнар үтү белән, муллаларның да вазифалары үзгәрә. Хәзерге заман мулласын ул төрле ракурстан карый: ул дин галиме, тормыш-көнитеш мәсьәләләрендә халыкның белемле киңәшчесе, милли мәсьәләләр белән хәбәрдар җәмәгать хадиме һ.б.лар. Бу максатларга ирешү өчен, мәдрәсәләрдә белем бирү системасын яңарту, реформалаштыру ихтыяҗы туа.

Н. Гасрый "рухи юлбашчылар"ны әзерләү проблемасын милли-иҗтимагый контекстта һәм күпмәдәниятле пространство кысаларында карый. Муллалар, руханиларның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен кирәк булган характер сыйфатларын, яңа күнекмәләр һәм белемнәр формалаштыру ноктасыннан ул иң беренче мәдрәсәләрдә белем бирүнең структурасын һәм күләмен ачыклый. Корьән, дин-шәригать кануннарыннан мәгълүматлы булу өчен дини фәннәрне укыту кирәклеге ассызыклана; тулы канлы милләт хезмәтчесе вазифасын үтәү милли телне, имляны, татар әдбиятын һәм тарих фәннәрен өйрәнүдән башка мөмкин түгеллеге әйтелә. Мөселман руханиеның Россия гражданы булуы сәбәпле, Ватан тарихыннан хәбәрдарлыгы да шарт итеп куела. Муллага "бер рух көтүчесе, җәмәгать юлбашчысы" вазифасын башкару өчен, аның, гомуми тарих, психология, иҗтимагый фәннәрдән белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиешлеге тәкрарлана.

"Исмәгыйль бәк Гаспринский вә гомуми әдәби тел" (1914) мәкаләсе Н. Гасрый гыйльми карашларының офыгын киңәйтеп җибәрә. Ул Исмәгыйль Гаспринскийның үлеменә 90 ел

тулу уңаеннан Ф. Гаффарова төзегән “Исмәгыйль бәк Гаспралы” китабына да урнаштырылган [Исмәгыйль бәк Гаспринский, 2004]. Язмада барлык төрки халыкларны берләштерү идеясе белән яшәгән Исмәгыйль бәк нәшер иткән “Тәрҗеман” газетасының телен бәяләү уңаеннан Н. Гасрыйның тел, аның асылы, үсеш үзенчәлекләре хакында карашлары гәүдәләнә. Ул телне милләтнең нигезе, аны яшәтүче һәм саклаучы мәдәниятнең бер өлеше дип карый. Исмәгыйль бәк эшчәнлегенең кыйммәтен төрек-татар милләте өчен “гомуми әдәби тел”не нигезләүдә билгели.

Төрки телләр үсеше закончалыкларына нигезләнеп, өч телне аерып чыгара: “Идел буе татарларының тел вә әдәбияты; Кавказ шивәсе вә әдәбияты; җәнүбә төрекләре теле”. Шушы телләрнең формалашу тарихын, төп хосусиятләрен, әдәбиятлары үсешен, гомуми әдәби телнең урынын һәм перспективасын билгели. Алар арасында, соңгы утыз ел эчендә барлыкка килеп, башкорт, мишәр, ногай, себер татарлары телләрен бер байрак астына туплаган, матур әдәбият тудырылган Идел буе татарларының телен аерып куя.

## Нәтиҗәләр

1. Н. Гасрый татар мәгърифәтчеләре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, И. Гаспралыларның иҗтимагый-фәлсәфи карашлары системасы тәэсирендә, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов әдәби мәктәпләрендә тәрбияләнгән икенче буын татар әдипләренең күренекле вәкиле булып тора.

2. Н. Гасрый бай һәм катлаулы тормыш юлы үтә. Россиянең һәм Төркиянең төрле баскыч дөньяви уку йортларында белем алып, теоретик әзерлекле, иҗади, эзләнүчән һәм күпкырлы шәхес булып җитешә һәм үзен татар халкына, милләтенә хезмәт итүгә багышлый.

3. Ул татар әдәби тәнкыйте, әдәбият тарихы, татар журналистикасы һәм публицистикасы тармакларында актив эшләп, XX гасыр башында татар халкының иҗтимагый-рухи һәм мәдәни яңарышына үзеннән зур өлеш кертә. Аның иҗаты “тизләтелгән үсеш юлы”на чыккан татар сүз сәнгате һәм миллилекне саклаган хәлдә ауропалашуга йөз тоткан милли мәдәният белән тыгыз бәйләнгән.

4. Н. Гасрый, гыйльми тикшеренүләрен иҗтимагый барыш, татар халкы тарихы белән тыгыз бәйләнештә алып барып, әдәбият-сәнгатьне, күренекле шәхесләрне милләткә хезмәт итү, милләткә файдалы булу ноктасыннан бәяли.

## Йомгак

Димәк, Нәҗип Гасрый, татар әдәбиятының классиклары һәм сәләтле галимнәре белән бергә, XX гасыр башында татар халкының рухи һәм мәдәни күтәрелешендә зур роль уйный. Ул – киңкырлы һәм талантлы шәхес итеп формалаштырып, калебләрендә туган халкының иҗтимагый һәм мәдәни яңарышына хезмәт итү теләге уятып та, әмма яңадан үзләрен һәлак иткән дәһшәтле һәм катлаулы XX гасыр татар зыялылары буынының берсе. Н. Гасрый әдәби-эстетик һәм дөньяга карашлары белән социаль һәм милли азатлык хәрәкәте юлбашчысы Г. Исхакыйга якын тора. Әдип үзенең гыйльми-тәнкыйди һәм публицистик эшчәнлегендә культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә, тарихилык һәм миллилек принципларына нигезләнә.

**Әдәбият**

*Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек*: 2 томда: 1 том / төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани. Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. 751 б.

*Әмирханов Р.* Фатих Әмирханов турында истәлекләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. 255 б.

*Бәширов Ф.* XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.

*Бикташев Р .И.* Литературное и публицистическое наследие Ахметзяна Биктимирова (начало XX века). Автореф. на соиск. ... к.филол.н. Казань, 2007. 31 с.

*Гасрый Н.* Исмәгыйль бәк Гаспринский һәм гомуми әдәби тел // Исмәгыйль бәк Гаспралы [Кереш мәкалә авт. һәм төз. Ф. Ю. Гаффарова; җаваплы мөх. Ф. М. Солтанов]. Казан: Алма-Лит, 2004. Б. 60-64 б.

*Гасрый Нәҗип* // Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррире М. Х. Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г. С. Сабирҗанов. Казан “ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты” дәүләт учреждениесе, 2010. 2 т: Г-Й. Б. 80.

*Гасрый Н.* Тукаев вафат // Идел. 1913. 5 апрель.

*Гасрый Н.* Әдәбиятымыз мөнәкъкыйдкә мохтаҗ // Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит.нәшр., 2008. Б. 238-241.

*Гасрый Н.* Яшьләр хәятыннан бер ләүхә // Ил. 1914. 2 гыйнвар (№10).

*Гасрый Н.* Шимали төрки әдипләреннән Гаяз Исхакый // Әсәрләр 15 томда. 8 т.: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары (1898-1917) [төз., текст һәм аңлат. әзерл., кереш сүз авт. Ф. Ибраһимова]. Казан: Татар. кит.нәшр., 2001. Б. 154–164.

*Гасрый Н.* Гыйффәт туташның шигырьләре // Ил. 1915. 5 март (№ 81); 11 март (№84).

*Гасрый Н.* “Хисметдин менла” (Акъегетзадә әсәре) Бер тәхлил әдәби // Аң. 1915. №9. Б. 189-194; №23-24. Б. 416-424.

*Гасрый Н.* Әдәбият мәйданында (Мәскәүдә СССР халыкларының үзәк нәшрияты нәшере, матур басмада, 110 битлек. Иптәш Галимҗан Нигъмәти әсәре) // Эшче. 1926. 20 гыйнвар (№749).

*Гасрый Н.* Мәдрәсә мәсьәләсе (съезд дикъкатенә) // Ил. 1914. 17 июнь (№31).

*Гасрый Н.* “Соңгыр хан түбәсе”ндә // Аң. 1916. №2. Б. 29-33.

*Гасрый Н.* Мәзарстанда // Аң. 1916. №5. Б. 78-82.

*Гасрый Н.* Гыйшкым хәрабәләре (Хикәя) // Аң. 1916. №7. Б. 114-118.

*Гилазов Т.Ш.* Рассказ Г. Ибрагимова «Один эпизод из жизни молодежи» в литературной критике 1910 –х годов // Филология и культура. Philology and Culture. 2017. № 2(48).

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Әдәбият белеменең бер тармагы буларак әдәби тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 т.: XX йөз башы / [төз. Р .Ф. Рахмани; фән. мөх. Р .К. Ганиева]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. Б. 428-453.

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит.нәшр., 2008. 254 б.

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Нәҗип Гасрыйның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә З. Бурнашева (Гыйффәт туташ) шигърияте // Фәнни язмалар - 2012: КФУ ның Филология һәм сәнгать институтының фәнни язмалары / Фән. мөх. Р. Р. Җамалетдинов. Казан: Казан университеты, 2012. Б. 84-91.

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Нәҗип Гасрый // Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш мөх. З. З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. Б.195.

*Җамал Вәлиди*: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз. Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

*Җәүһәрова Ф.Х* Әстерхан төбәгендә татар әдәбияты (XIX-XX йөз башы). Казан: Мәгариф, 2003. 127 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. 255 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр сигез томда. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр хезмәтләр (1910-1933) [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Хәсәнов М. Х., Гайнанов Р. Р.]. Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. 615 б.

*Ибраһимов Г.* Матбугат вә әдәбиятымызның барышы (еллык хисап урынына) // Әсәрләр: 15 томда. Академик басма 6 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1917) [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З. Г. Мөхәммәтшин; фән. мөх. Т. Ш. Гыйлаҗев]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2019. Б. 192-202.

*Исхакый Г.* Гаяз Исхакыйның татар әдәбияты турындагы доклады // Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре [төз. З Рәмиев, Ф. Ибраһимова; текст. әзерл. Ф. Ибраһимова; аңл. һәм иск. әзерл. З. Рәмиев; фәнни мөх. Ф. Мусин]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. Б. 190-203.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902-1914) [төз. З. Рәмиев, Ф. Ибраһимова; текст. әзерл. Ф. Ибраһимова; аңл. һәм иск. әзерл. З. Рәмиев; фәнни мөх. Ф. Мусин]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. 447 б.

Исхакый Г. Әсәрләр 15 томда. 8 т.: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары (1898-1917) [төз., текст һәм аңлат. әзерл., кереш сүз авт. Ф. Ибраһимова]. Казан: Татар. кит.нәшр., 2001. 447 б.

*Исхакый Г.* Әсәрләр 15 томда. 11 т.: публицистика (1934-1936) [томны төз., текст., иск. һәм һәм аңлат. әзерл.; кереш мәкалә авт. З. Мөхәммәтшин; фәнни мөх. З. Рәмиев]. Казан: Татар. кит.нәшр., 2011. 399 б.

*Исхакый Г.* Максим Горькийга (1911, 6 гыйнвар) // Әсәрләр: 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар (1902-1954) [томны төз., текст һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. 11 б.

*Исхакый Г.* Әсәрләр 15 томда. 15 т.: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында истәлекләр һәм мәкаләләр (1923-1990) [томны төз., текст., иск. һәм һәм аңлат. әзерл. Г. Ханнанова, Р. Кадыйров]. Казан: Татар. кит.нәшр., 2014. 527 б.

*Мәрданов Р.* “Шура” журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан: Рухият, 2001. 152 б.

*Мирасыбызны туплау юлында* [XX йөз башы татар балалар әдәбиятыннан] / төз. Ф. Ибраһимова. Казан: “Иман” нәшрияты, 2010. 200 б.

*Мусабекова Р.Р.* Сагит Сунчелей: судьба и творчество [науч. ред. Р. К. Ганиева; рец. Х. Ю. Миннегулов, Т. Ш. Гилазов]. Казань: Изд-во: “УҢЫШ”, 2001. 157 с.

*Мухамадиев Р.С.* Проблемы формирования татарской литературной критики (1905-1917). Казань: Татар. кн. изд-во. 1982. 144 с.

*Неджиб (Гасри Н.)* Пробуждение русских татар и их литература // Современник. 1914. №10. С. 166-177.

*Галимҗан Нигъмәти*: тормышы, язмышы, фәнни-методик эшчәнлеге / Т. Ш. Гыйлаҗев редакциясендә. Казан: “Бриг” нәшрияты, 2018. 252 б.

*Рахимкулова М.* Медресе “Хусаиния” в Оренбурге. 2-ое дополненное юбилейное издание, посвященное 160-летию Ахмет бая Хусаинова. Оренбург, 1997. 251 с.

*Рәми И.Г., Даутов Р.Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. 399 б.

*Рәмиев З.З.* Кереш // Татар шигърияте: XX гасыр башы. Казан: Мәгариф, 2004. Б. 3-8.

*Рәхмәти С.* Гыйффәт туташ мәктүбе мөнәсәбәте илә // Йолдыз. 1915. 2 октябрь.

*Сәгъди Г.* Татар шагыйрьләре арасында Тукай // Безнең юл. 1923. №8 – 9. Б. 2-7.

*Сәгъди Г.* Бездә әдәби тәнкыйть (Үктәбернең унъеллыгына). Казан: Безнең юл. 1927. 22 б.

*Сәгъи Г.* Символизм турында. Мәскәү: Центриздат, 1932. 135 б.

*Сөнгати Г.* Шигырьләр һәм проза. Казан: “Меддок” нәшрияты, 2007. 184 б.

*Сүнчәләй С.* Әсәрләр һәм хатлар [Төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З. Рәмиев]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. 367 б.

*Татар әдәбияты тарихы.* Алты томда. 1 том / Урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 567б.

*Татар хикәяләре* [Китапны төз., текст. әзерл. һәм кереш мәкалә авт. Д. Ф. Заһидуллина]. Казан: Мәгариф, 2007. 399 б.

*Татар шигърияте: XX гасыр башы.* Казан: Мәгариф, 2004. 447 б.

*Тукай – ядкәрләрдә*: 2 томда. 1 т. : Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / Төзүчеләр: Р. Ф. Исламов, филология фәннәре докторы, Җ. С. Миңнуллин, тарих фәннәре кандидаты. Казан: Җыен, 2015. 968 б.

*“Уйласам уй, сызлый күңлем, сызлый җан...”.* Сәгыйть Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗатына карата яңа мәгълүматлар [төз.-авт. Ч. Зарипова-Четин; фән мөх. А. Саяпова]. Казан: “Яңалиф” нәшрият йорты, 2005. 203 б.

*Фәйзи М.* Әсәрләр [төз. һәм кереш мәкалә авт. Т. Ш. Гыйлаҗев]. Казан: Мәгариф, 2007. 295 б.

*Хәсәвнех А.Ә.* Ил // Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррире М. Х. Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г. С. Сабирҗанов. Казан “ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты” дәүләт учреждениесе, 2010. 2 т: Г-Й. 536 б.

*Эпик шигърият: XX йөз башы* / төз. Ф. З. Яхин. Казан: Татарстан республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. 463 б.

*Яхин Ф.* XX йөз башы татар эпик шигърияте // Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф. З. Яхин. Казан: Татарстан республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. Б. 5-16.

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ Н. ГАСРИ В ЛИТЕРАТУРНОМ И КУЛЬТУРНОМ КОНТЕКСТЕ НАЧАЛА XX ВЕКА

**Тагир Шамсегалиевич Гилазов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
tgilazov@bk.ru.

В статье систематизированы сведения о жизни и деятельности Неджиба Гасри, сыгравшего огромную роль в подъеме культурной и литературной жизни татарского народа в начале XX века. Объектом исследования послужили его статьи, посвященные истории татарской литературы, татарской критики, национальной культуры и просвещения, а также выдающимся деятелям. Общественные взгляды Н. Гасри, его эстетические ориентиры рассматриваются в контексте развития культуры и литературы начала XX века. Пристальное внимание уделяется связи духовного наследия писателя с восточными и западными литературными традициями.

Предпринята попытка создания научной биографии Н. Гасри на основе систематизации отдельных фактов. Впервые в оборот вводится ряд новых источников: статьи писателя, воспоминания о нем. Основные методы исследования: сравнительно-исторический, типологический и герменевтический с опорой на традиции и принципы культурно-исторической школы.

**Ключевые слова:** национальное возрождение, литературные взаимосвязи, культурно-историческая школа, общественная мысль, татарская литература, литературная критика, история литературы.